Изге җанлы дусларыбыз Финат Мөхәммәдиев һәм Шамил Шәкуровларның туган авылына язылган җырыбыз

# Сагындым, Күзәем

Рамил Чурагулов сүзләре

Фәнир Галимов көе




1

Күзәемә кайтам көзен,
Бар табигать алтында.
Ак каеннар кулын суза,
Алар мине сагынган.

*Кушымта:*

Әй, Күзәем, матур көзен,
Язын, җәен, кышларын,
Җир читләрендә булсам да
Синдәй авыл күрмәдем.

2

Ут уйнатып эшлибез без
Без – гармунчы, без – җырчы.
Биюен дә биибез без,
Имән идән сынганчы.

3

Батыр уллар, гүзәл кызлар,
Арттыра авыл данын.
Күзәйдә тик бер булсаң да
Гомер ашкынып җаның.